| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>АЛЕКСЕЕВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>АЛЕКСЕЕВСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

28.05.2020 п.г.т.Алексеевское № 186

**«Алексеевск муниципаль районында кече һәм урта эшкуарлык субъектларына мөлкәти ярдәм күрсәтү мәсьәләләре буенча эш төркеме төзү турында» 2020 елның 19 мартындагы 109 номерлы башкарма комитет карарына үзгәреш кертү хакында**

Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре буенча 2020 елның 30 апреленнән нәтиҗәне карап, коррупциячел факторларны бетерү максатларында

**карар кылам:**

1. «Алексеевск муниципаль районында кече һәм урта эшкуарлык субъектларына мөлкәти ярдәм күрсәтү мәсьәләләре буенча эш төркеме төзү турында» 2020 елның 19 мартындагы 109 номерлы башкарма комитетының 2 нче кушымтасына түбәндәге эчтәлекле үзгәрешләр кертергә:

- 4.9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.9. Әгәр эш төркеме утырышында эшче төркем әгъзаларының гомуми санының кимендә яртысы катнашса, эш төркеме утырышы тулы хокуклы дип санала»;

- 4.14 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.14. Эш төркеме рәисе карары буенча утырыш читтән торып үткәрелә. Утырышны читтән торып үткәрү турында карар кабул иткәндә, сорашып тавыш бирү юлы белән эшче төркем әгъзаларына мәҗбүри рәвештә эш төркеме секретаре тарафыннан хәбәр ителә, шул ук вакытта читтән торып тавыш бирүгә чыгарылган мәсьәләләр буенча, утырышны читтән торып үткәрү турындагы карарда күрсәтелгән вакытка кадәр дәлилләнгән позиция бирелә».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **Н.К. Кадыйров**